# КАРАР

**30 ноябрь, 2023 ел** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге Тарлау авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 28 ноябрендә 19.30 сәгатьтә һәм 2023 елның 30 ноябрендә 19.30 сәгатьтә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Ядегәр авыл җирлеге Тарлау авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Тарлау авылындагы юлларны кышкы-җәйге чорда карап тоту һәм проект-смета документларын эшләү, килешү буенча эш өчен түләү;
- Тарлау авылының Пушкин урамы юлларын вак таш салып төзү һәм ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча түләү;
- Тарлау авылына энергия саклаучы лампалар, светодиодлы яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау һәм карап тоту;
- чишмәләрне төзекләндерү, карап тоту, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу һәм чишмәне төзекләндерү һәм тоту буенча башка эш төрләре;
- су башнясы өчен насос сатып алу һәм урнаштыру, су белән тәэмин итү трассасын төзү һәм ремонтлау, һәм проект-смета документларын эшләү, килешү буенча эш өчен түләү;
- «Сабантуй» уздыру урыны территориясен төзекләндерү, һәм проект-смета документларын эшләү, килешү буенча эш өчен түләү;
- Тарлау авылы юлларына асфальт җәю, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; һәм экспертиза үткәрү, килешү буенча түләү;

- Тарлау авылы зиратларын карап тоту, материаллар, кораллар сатып алу һәм коймалау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча түләү;
- Тарлау авылы мәчете каршында машина куюю урыны төзү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; һәм экспертиза үткәрү, килешү буенча түләү;
- халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү, һәм проект-смета документларын эшләү, килешү буенча эш өчен түләү;

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 117 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 62 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 62 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Тарлау авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Ядегәр авыл җирлеге Тарлау авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Тарлау авылындагы юлларны кышкы-җәйге чорда карап тоту һәм проект-смета документларын эшләү, килешү буенча эш өчен түләү;
- Тарлау авылының Пушкин урамы юлларын вак таш салып төзү һәм ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча түләү;
- Тарлау авылына энергия саклаучы лампалар, светодиодлы яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, ремонтлау һәм карап тоту;

- чишмәләрне төзекләндерү, карап тоту, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу һәм чишмәне төзекләндерү һәм тоту буенча башка эш төрләре;

- су башнясы өчен насос сатып алу һәм урнаштыру, су белән тәэмин итү трассасын төзү һәм ремонтлау, һәм проект-смета документларын эшләү, килешү буенча эш өчен түләү;

- «Сабантуй» уздыру урыны территориясен төзекләндерү, һәм проект-смета документларын эшләү, килешү буенча эш өчен түләү;

- Тарлау авылы юлларына асфальт җәю, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; һәм экспертиза үткәрү, килешү буенча түләү;

- Тарлау авылы зиратларын карап тоту, материаллар, кораллар сатып алу һәм коймалау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча түләү;

- Тарлау авылы мәчете каршында машина кую урыны төзү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; һәм экспертиза үткәрү, килешү буенча түләү;

- халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү, һәм проект-смета документларын эшләү, килешү буенча эш өчен түләү;

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип исәпләргә.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәсен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ruадресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Ядегәр
авыл җирлеге башлыгы А.Н. Фәйзуллин